# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Халыкны эш белән тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

**1 статья.** «Халыкны эш белән тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына (1998 елның 3 июлендәге 1703 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 3; 1994, № 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8, (I өлеш); Республика Татарстан, 2001, 31 июль, № 151) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. Законның тексты буеннан-буена тиешле килешләрдәге һәм саннардагы «эш белән тәэмин итү һәм хезмәт буенча дәүләт органы» сүзләрен тиешле килешләрдәге һәм саннардагы «халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органы» сүзләренә алмаштырырга.

2. 2 статьяда:

икенче һәм дүртенче абзацларны төшереп калдырырга;

өченче, бишенче-унынчы абзацларны тиешенчә икенче-сигезенче абзацлар дип санарга;

өченче абзацта «җәмәгать эшләреннән гайре (җәмәгать эшләрендә катнашучы һәм әлеге Законның 4 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән гражданнардан тыш)» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «яки башка сәбәпләр» сүзләрен «хәрби җыелуларга чакыру, хәрби хезмәткә әзерләү, дәүләтнең башка вазыйфаларын үтәү яисә башка җитди сәбәпләр белән бәйле гамәлләргә җәлеп итү» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «эчке эшләр органнарында» дигән сүзләрдән соң «,җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә һәм органнарында» сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ярдәмче промыселларда эшләүчеләр һәм продукциясен шартнамәләр буенча сатучылар, шулай ук граждан-хокукый характердагы, предметлары эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтүләр булган шартнамәләр буенча, шул исәптән индивидуаль эшкуарлар белән төзелгән шартнамәләр, авторлык шартнамәләре буенча эшләр башкаручылар;»;

түбәндәге эчтәлектә тугызынчы абзац өстәргә:

«оешмаларның гамәлгә куючылары (катнашучылары), моңа иҗтимагый һәм дини оешмаларның (берләшмәләрнең), хәйрия һәм бүтән төрле фондларның, шушы оешмаларга карата мөлкәти хокуклары булмаган юридик затлар берләшмәләренең (ассоциацияләренең һәм берлекләренең) гамәлгә куючылары (катнашучылары) керми.».

3. 3 статьяның 3 пунктындагы алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«суд карары буенча ирегеннән мәхрүм итмичә генә төзәтү эшләренә, шулай ук ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәр.».

4. 4 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Хезмәт турындагы законнарның таләпләренә җавап бирүче түләүле эш, алдан әзерлекне таләп итүче яисә таләп итмәүче (гражданнарның ничә яшьтә булуларын һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып) вакытлы характердагы һәм җәмәгать эшләрен дә кертеп, түбәндәге гражданнар өчен яраклы эш дип санала:

беренче тапкыр эш эзләүчеләр (элек эшләмәгәннәр) эшсезлек башланганчы бер ел эчендә хезмәт дисциплинасын бозган өчен һәм Россия Федерациясе законнарында каралган башка гаепле гамәлләре өчен бер мәртәбәдән артыграк эштән чыгарылганнар, элегрәк эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнгәннәр, озакка сузылган (бер елдан да артыграк) тәнәфестән соң хезмәт эшчәнлеген яңартырга омтылганнар, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан укырга җибәрелгәннәр һәм гаепле гамәлләре өчен укудан чыгарылганнар;

эшсезлекнең башлангыч (12 айлык) чоры узганнан соң булган һөнәре (белгечлеге) буенча белгечлеген арттырудан (торгызудан), янәшә һөнәр алудан яисә янадан әзерләүдән баш тартучылар;

халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында 18 айдан артыграк исәптә торганнар, шулай ук өч елдан артыграк эшләмичә торганнар;

сезонлы эшләр тәгәлләнгәннән соң халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткәннәр.».

5. 5 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары белән бергәләп халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшлиләр һәм гамәлгә ашыралар.».

6. 22 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22 статья. Эш белән тәэмин ителмәгән халыкка эш белән тәэмин ителүдә һәм социаль яклануда ярдәм күрсәтү гамәлләрен финанслау

Эш белән тәэмин ителмәгән халыкка эш белән тәэмин ителүдә һәм социаль яклануда ярдәм күрсәтү гамәлләрен финанслау федераль бюджет, Татарстан Республикасының Республика бюджеты, җирле бюджетлар акчалары, шулай ук бюджеттан тыш башка чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Эш белән тәэмин ителмәгән халыкка эш белән тәэмин ителүдә һәм социаль яклануда ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәте гамәлләрен тормышка ашыруга юнәлгән акчаларны булдыру һәм тоту законнар нигезендә башкарыла.».

7. 24 статьяда:

1 пунктта:

беренче абзацта «Җирле администрацияләр һәм» сүзләрен «Җирле администрацияләр,» сүзләренә алмаштырырга;

икенче һәм өченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

«Җәмәгать эшләре дигәндә социаль файдалы юнәлеше булган һәм эш эзләүче гражданнарга өстәмә социаль ярдәм күрсәтү сыйфатында оештырылучы һәркем булдырырлык хезмәт эшчәнлеге күз алдында тотыла.

Һәлакәтләрнең, табигый бәла-казаларның, афәтләрнең һәм башка гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерү белән бәйле һәм хезмәткәрләрнең махсус әзерлеген, шулай ук аларның кыска вакыт эчендә квалификацияле һәм җаваплы гамәлләрен таләп итүче эшчәнлек җәмәгать эшләренә кертелми.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җәмәгать эшләрендә катнашырга теләүче затлар белән вакытлы хезмәт шартнамәсе төзелә. Мондый шартнамәне төзүдә өстенлекле хокукка эшсезлек буенча пособие алмаучы эшсез гражданнар, эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында алты айдан да артыграк исәптә торучы эшсез гражданнар ия була. Эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнар шулай ук җәмәгать эшләрендә катнашу хокукына ия булалар.

Гражданнарның җәмәгать эшләрендә катнашулары бары тик алар ризалыгы белән генә рөхсәт ителә. Җәмәгать эшләренә җибәргәндә гражданнарның сәламәтлеге, яше, һөнәри һәм башка индивидуаль үзенчәлекләре исәпкә алына. Гражданның җәмәгать эшләрендә катнашуы турындагы вакытлы хезмәт шартнамәсе даими яисә вакытлы эшкә урнашканда аның тарафыннан вакытыннан алда өзелергә мөмкин.»;

3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшсез гражданнарның җәмәгать эшләрендә катнашу чорында аларның эшсезлек буенча пособие алу хокукы сакланып кала (моңа әлеге Законның 4 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән җәмәгать эшләрендә катнашучы гражданнар керми).»;

5 пунктта «җирле бюджет һәм Татарстан Республикасының эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фонды» сүзләрен «федераль бюджет, Татарстан Республикасының Республика бюджеты һәм җирле бюджетлар» сүзләренә алмаштырырга.

8. V бүлекне төшереп калдырырга.

9. 26 статьяда:

2 пунктта:

«Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү дәүләт фондына мәҗбүри иминләштерү кертемнәрен күчерү һәм» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

«мәҗбүри түләү» дигән сүзләргә кадәр «җирле бюджетларга» дигән сүзләр өстәргә;

4 пунктта «Эш белән тәэмин итү дәүләт фондына» сүзләрен «Республика бюджетына» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның беренче өлешендә «Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү дәүләт фондына» сүзләрен «җирле бюджетларга» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «Эш белән тәэмин итү дәүләт фондына» сүзләрен «Республика бюджетына» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктны төшереп калдырырга.

10. 28 статьяның 3 пунктын төшереп калдырырга;

4 пунктны 3 пункт дип санарга.

11. 33 статьяның 3 пунктында «Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү дәүләт фондыннан» сүзләрен «федераль бюджеттан» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 25 октябре
№ 1145